| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУСЛЮМОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МӨСЛИМ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.05.2021 с. Муслюмово №214

**Социаль түләү күләмен хисаплап чыгару өчен Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативы турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 289 номерлы карары белән расланган «2014-2019 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак - коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» Дәүләт программасының «2014-2019 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын һәм Татарстан Республикасы Мөслим мунициПаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 14 гыйнварындагы 2 нче карары белән расланган «2021 - 2026 елларга Мөслим муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мослим муниципаль районы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының торак шартларын яхшырту чараларын үткәрүгә социаль түләүләр күләмен хисаплап чыгару өчен торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясен түбәндәгечә расларга:
- Мослим авылында күпфатирлы торак йортларның 1 кв.м очен - 28889 сум;
- Мослим авылында индивидуаль торак төзелешенең 1 кв.м очен - 25692 сум;
- Мослим муниципаль районында шәхси торак төзелешенең 1 кв.м өчен - 11002 сум;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматыныц рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында (https://muslumovo.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Мослим муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Т. Демидов**